# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Сәүдә (эшләр башкару, хезмәт күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендә хокук бозган өчен, штрихлы мәҗбүри кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозган өчен административ җаваплылык турында

Әлеге Закон сәүдә (эшләр башкару, хезмәт күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендә хокук бозган, штрихлы мәҗбүри кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозган өчен юридик затларның, индивидуаль эшкуарлар сыйфатында теркәлгән гражданнарның һәм урындагы затларның административ җаваплылыгын билгели.

<u>1 статья.</u> Әлеге Законның гамәли чикләре

Әлеге Законда каралган хокук бозулар өчен, әгәр бу хокук бозуларның үзенчәлеге законнар нигезендә җинаять җаваплылыгына китермәсә, административ җаваплылык билгеләнә.

Әлеге Законның гамәлдә булуы Татарстан Республикасының башка законнарында административ җаваплылык билгеләнгән хокук бозуларга кагылмый.

<u>2 статья.</u> Сәүдә кагыйдәләрен бозу

Сәүдәнең билгеләнгән кагыйдәләрен бозган килеш товарлар саткан өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең әчтән алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

3 статья. Ирекле сату тыелган яисә чикләнгән товарлар белән законсыз сәүдә итү

Законнар нигезендә ирекле сату тыелган яисә чикләнгән товарлар белән законсыз сәүдә иткән өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга, товарларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. Сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмаган товарларны сату

Сыйфаты, комплектлылыгы һәм төргәге буенча стандартлар, техник шартлар таләпләренә һәм үрнәкләргә (эталоннарга) туры килми торган товарларны саткан өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. Яраклылык чоры узган товарларны сату

Яраклылык чоры узган товарларны саткан өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга, товарларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

6 статья. Билгеләнгән санитар кагыйдәләрне бозган килеш азык-төлек товарларын сату, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү

Билгеләнгән санитар кагыйдәләрне бозган килеш азык-төлек товарларын саткан, эшләр башкарган, хезмәт күрсәткән өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең биштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

7 статья. Документсыз товарларны сату

Товарларны әзерләүчесе, китереп торучысы яисә сатучысы турындагы белешмәләр булырга тиешле документларсыз саткан өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Махсус кагыйдәләрне кулланучылар игътибарына җиткерү тәртибен бозып товарлар сату, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү

Кулланучы гомеренең, сәламәтлегенең һәм мөлкәтенең иминлеген тәэмин итү өчен, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өчен үтәлешләре мәҗбүри булган махсус кагыйдәләрне кулланучылар игътибарына җиткерү тәртибен бозып товарлар саткан, эшләр башкарган, хезмәт күрсәткән өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга (әзерләүчеләргә, башкаручыларга) хезмәт өчен түләүнең өчтән алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

9 статья. Кулланучыларны алдау

Товарларны киметеп санаган, үлчәгән өчен, сатып алучыдан артык акча алган өчен, товарның (хезмәт күрсәтүнең) куллану үзенчәлекләре яисә сыйфаты турында ялган мәгълүмат биргән өчен яки кулланучыларны башкача алдаган өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар (башкаручылар) сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең бердән алып утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

10 статья. Мәҗбүри сертификацияләнергә тиешле товарлар сату, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү кагыйдәләрен бозу

Мәҗбүри сертификацияләнергә тиешле товарларны тәңгәллек

сертификатыннан һәм (яисә) тәңгәллек тамгасыннан башка саткан, эшләр башкарган,хезмәт күрсәткән өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга (әзерләүчеләргә, башкаручыларга), товарларын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең уннан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

Сертификацияләнгән, әмма тәңгәллекләренә сертификацияләү буенча норматив документлар таләпләренә җавап бирми торган товарларны саткан, эшләр башкарган, хезмәт күрсәткән өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга (әзерләүчеләргә, башкаручыларга) хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

Мәҗбүри сертификацияләнергә тиешле товарларны алар белән бергә бирелүче техник документларында сертификацияләү турында яисә шушы товарлар туры килергә тиешле норматив документлар турында белешмәләрне күрсәтмичә саткан өчен йә шушы белешмәләрне кулланучыларга җиткермәгән өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең бердән алып ун минималь күләменә кадәр штраф салына.

<u>11 статья.</u> Мәҗбүри сертификацияләү кагыйдәләрен бозу

Мәҗбүри сертификацияләнергә тиешле товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) тәңгәллек сертификаты сертификацияләү органнарының урындагы затлары тарафыннан нигезсез бирелгән, расланган, туктатып торылган, юкка чыгарылган яисә гамәлдә булуы нигезсез яңартылган өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең унбиштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

Мәҗбүри сертификацияләнергә тиешле товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) аккредитацияләнмәгән сертификацияләү органы тарафыннан тәңгәллек сертификаты бирелгән өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең егерме биштән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

12 статья. Сертификация сынауларын уздыру кагыйдәләрен бозу

Сынау лабораторияләре (үзәкләре) тарафыннан, норматив документларның таләпләре бозылып, тәңгәллек сертификатын нигезсез бирүгә китерерлек сертификация сынаулары уздырылган өчен -

сынау лабораторияләренең (үзәкләренең) урындагы затларына хезмәт өчен түләүнең егермедән алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

13 статья. Лицензияләнергә тишле эшчәнлекне лицензиясез яисә лицензия шартларын бозып гамәлгә ашыру

Лицензияләнергә тиешле эшчәнлекне лицензиясез башкарган өчен -

урындагы затларга һәм индивидуаль эшкуарлар сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына

Лицензияләнергә тиешле эшчәнлекне лицензия шартларын бозып башкарган өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр, индивидуаль эшкуарлар сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

14 статья. Лицензияләнергә тиешле эшчәнлекне лицензияне теркәтмичә башкару

Лицензияләнергә тиешле эшчәнлекне лицензияне теркәтмичә башкарган өчен -

урындагы затларга һәм индивидуаль эшкуарлар сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең утыздан алып илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

15 статья. Лицензияләрне бирү, теркәү, туктатып тору һәм юкка чыгару кагыйдәләрен бозу

Лицензияләүче органнар тарафыннан лицензияләрне бирү,

теркәү, туктатып тору һәм юкка чыгару кагыйдәләре бозылган өчен -

урындагы затларга хезмәт өчен түләүнең биштән алып утыз минималь күләменә кадәр штраф салына.

16 статья. Товарларның штрихлы мәҗбүри кодлаштыру буенча билгеләнгән тәртибен бозу

Товарларның штрихлы мәҗбүри кодлаштыру буенча билгеләнгән тәртибен бозган өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең өчтән алып егерме биш минималь күләменә кадәр штраф салына.

17 статья. Вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан товарларга, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә билгеләнә яисә җайга салына торган бәяләрне бозу

Вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан билгеләнә яисә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны), шул исәптән беркетелгән бәяләрне (тарифларны), иң чик бәяләрне (тарифларны), бәяләр (тарифлар) үзгәртүнең иң чик коэффициентларын, сату өстәлмәләренең (өстәмә бәяләрнең) иң чик күләмнәрен бозган өчен, алдан каралмаган сату өстәлмәләрен (өстәмә бәяләрне) керткән өчен, шулай ук вәкаләтле дәүләт органнары белән законнар нигезендә катгый рәвештә килештерелергә тиешле бәяләрне (тарифларны) билгеләнгән тәртиптә алар белән килештермәгән өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-әзерләүчеләр (башкаручылар, сатучылар) сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

18 статья. Кулланучыларның товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен өстенлекле түләү ташламаларына (скидкаларына) хокукларын бозу

Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен өстенлекле түләү ташламаларын (скидкаларын) законнарда билгеләнгән күләмнән аз-

рак биргән яисә бөтенләй бирмәгән өчен -

юридик затларга, индивидуаль эшкуарлар-сатучылар (әзерләүчеләр, башкаручылар) сыйфатында теркәлгән гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

19 статья. Кулланучылар хокукларын яклау буенча вәкаләтле дәүләт органнарының законлы күрсәтмәләрен үтәмәү

Татарстан Республикасы Кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт комитетының, аның территория (район, шәһәр) комитетларының һәм Татарстан Республикасы Кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт комитеты Дәүләт транспорт инспекциясенең һәм аның төбәк бүлекчәләренең сәүдә (эшләр башкару, хезмәт күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендәге хокук бозуларны, мәҗбүри штрихлы кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозуларны бетерү турындагы законлы күрсәтмәләре урындагы затлар, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар сыйфатында теркәлгән гражданнар тарафыннан вакытында үтәлмәгән өчен -

аларга хезмәт өчен түләүнең йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

20 статья. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турында беркетмәләр Татарстан Республикасы Кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт комитетының, аның территория (район, шәһәр) комитетларының һәм Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт комитеты Дәүләт транспорт инспекциясенең һәм аның төбәк бүлекчәләренең, эчке эшләр органнарының, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясенең, Россия Федерациясе салым полициясенең Татарстан Республикасы буенча Федераль хезмәт идарәсенең, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитетының шуңа вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан төзелә.

96



21 статья. Сәүдә (эшләр башкару, хезмәт күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү әлкәсендә, штрихлы мәҗбүри кодлаштыру тәртибендә һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасында административ хокук бозулар турындагы эшләрне карарга вәкаләтле булган органнар (урындагы затлар)

Әлеге Законның 3,5 һәм 10 (1 өлеш) статьяларында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр район (шәһәр) судлары тарафыннан карала.

Әлеге Законның 2,4,7-9,10 (2,3 өлешләр), 13-19 статьяларында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт комитеты, аның территория (район, шәһәр) комитетлары һәм Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт комитетының Дәүләт транспорт инспекциясе, аның тәбәк бүлекчәләре тарафыннан карала.

Әлеге Законның 11-12 статьяларында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт комитеты тарафыннан карала.

Әлеге Законның 6 статьясында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитеты тарафыннан карала.

Әлеге статьяның 2,3 һәм 4 өлешләрендә күрсәтелгән органнар тарафыннан административ хокук бозулар турындагы эшләрне орган җитәкчесе карый.

22 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда карала.

23 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча карарларга шикаять белдерү

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча вәкаләтле органнарның карарларына законнарда билгеләнгән тәртиптә югарырак органга яисә судка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

24 статья. Штрафлардан килгән суммаларны бүлү

Әлеге Законның 2-18 статьяларында каралган штрафлардан килгән суммаларның 50 проценты - хокук бозулар башкарылган урын буенча шәһәр һәм район бюджетларына, 50 проценты Татарстан Республикасының республика бюджетына җибәрелә.

Әлеге Законның 19 статьясында каралган штрафлардан килгән суммалар Татарстан Республикасының республика бюджетына җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 3 июле
N 1701